**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КРУГЛОЕ ПОЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«08» ноябрь 2019 ел Круглое Поле п. № 57/1

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 16 октябрь № 44/1 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә» үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Круглое Поле авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Э.Р. Низамиева

Татарстан Республикасы Тукай
муниципаль районы «Круглое Поле
авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
Советының 2019 елның 08 ноябрь
57/1 санлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге уставы нигезендә эшләнгән.

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында торак пункт территориясендә даими яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган кешеләр катнашырга хокуклы.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ихтыяри һәм ирекле.

1.4. Гражданнар җыенда шәхсән катнаша һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.

1.5. Гражданнар җыены халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры хәл итү максатыннан үткәрелә.

1.6. Торак пунктта әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия булган халыкның яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены этаплап уздырыла.

**Гражданнар җыены вәкаләтләре**

1.7. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

составына күрсәтелгән торак пункт кергән җирлек чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, күрсәтелгән торак пункт территориясенең башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертелүенә китергәндә;

җирлек составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында гражданнар җыены, шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздырганда, конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатында үткәрелергә мөмкин.

**Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.8. Жыенны үткәрү муниципаль берәмлек Башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.9. Җыен әзерләү һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар җирлек бюджеты хисабына башкарыла.

## 2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе

Гражданнар җыены үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктта гражданнар җыенын үткәрү инициативасы белән чыга ала:

- муниципаль берәмлек Башлыгы;
- сайлау хокукына ия булган, торак пунктта яшәүчеләрнең гражданнар җыенында катнашырга хокуклы 10 кешедән ким булмаган төркеме (ягъни торак пункт территориясендә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә житкән эшкә сәләтле Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук торак пункт территориясендә яшәүче һәм Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда хокукларга ия чит ил гражданнары);

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы имзалар кәгазе яисә җыен үткәрү инициативасын чыгару турында карар кабул ителгән инициатив төркем җыелышының беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелергә, аларда түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

- гражданнар җыенына чыгарылучы сораулар;
- гражданнар җыенын үткәрергә тәкъдим ителгән вакыт;
- гражданнар җыенын чакыру турында инициативаны хуплаучы һәр гражданның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне; паспорт яки аны алыштыручы документның сериясе һәм номеры; имзасы һәм имза кую вакыты.

2.3. Җыен чакыру инициативасын хуплап җыярга кирәкле имзалар саны торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, сайлау хокукына ия даими яшәүче гражданнар саныннан 5 процент тәшкил итә, ләкин 10 имзадан да ким булырга тиеш түгел.

2.4. Язылу кәгазьләре, таныклау датасын, фамилиясен, атасының исемен, туган көнен, паспорт яки аны алыштыручы документның номерын һәм сериясен, яшәү урынын күрсәтеп, имзалар җыючы зат тарафыннан таныклана һәм муниципаль берәмлек Башлыгына җибәрелә.

### Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены җирлек Советы карары белән, ә муниципаль берәмлек Башлыгы инициативасы буенча – муниципаль берәмлек Башлыгы карары белән барлык кирәкле документлар кергән көннән 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Муниципаль берәмлек Башлыгы яисә җирлек Советы, максатка ярашсызлыгын сәбәп итеп, гражданнар җыенын үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

2.7. Гражданнар җыенына (гражданнар җыены этапларына) чыгарылган мәсьәлә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәскә тиеш. Гражданнар җыены соравы бер генә мәгънәдә аңларлык итеп формалаштырылырга тиеш.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү, аны күчерү турында карарны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе авыл җирлеге уставы белән билгеләнә.

Муниципаль берәмлек Башлыгының яисә җирлек Советының гражданнар җыенын үткәрү турында карарында түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә; гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе турында белешмәләр.

2.9. Авыл җирлеге Башкарма комитеты муниципаль берәмлек Башлыгының яки җирлек Советының гражданнар җыенын үткәрү турында карары нигезендә сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлеген төзи; гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; гражданнар җыены турында муниципаль берәмлек халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән хәбәр итә.

Авыл җирлеге Башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәрү өчен бина бирергә тиеш.

2.9.1. Гражданнар җыенын этаплап үткәрү барышында торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү һәм халык җыенын үткәрү датасын билгеләү территория, вакыт билгеләре буенча мөмкин.

2.9.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта күрсәтелә.

2.9.3. Торак пункт халкына гражданнар җыены (гражданнар җыены этаплары) вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр ителә. Гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) билгеләү турында карар, гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) үткәрү вакыты һәм урыны гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә сонга калмыйча басылып чыгарга (халыкка житкерелергә) тиеш. Гражданнар җыены этапларын үткәрү вакыты һәм урыны гражданнар җыенын билгеләү турында бер карарда күрсәтелә.

2.9.4. Гражданнар җыенын этаплап уздыру очрагында, җыен гражданнар җыенын уздыру турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта
этаплап уздырыла. Гражданнар җыены этапларын күчергән очракта, гражданнар җыены этапларын күчерү турында карар гражданнар җыенын уздыру билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә җыен үткәрелергә тиешле айлык чорны исәпкә алып кабул ителергә тиеш.

2.9.5. Гражданнар җыенында катнашучы һәр кеше гражданнар җыенын үткәрү датасына кадәр 5 көннән дә сонга калмыйча, авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыенына чыгарыла торган әлеге нигезләмәнең 2.9 пунктында күрсәтелгән материаллар белән танышырга хокуклы.

2.10. Гражданнар җыены турында нигезләмә нигезендә гражданнар җыенын үткәрү датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Гражданнар җыены датасын күчерү турында карар җыенны үткәрү билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

### 3. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар муниципаль берәмлек Башлыгы тарафыннан торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучы затларны теркәү өчен вәкаләтләр бирелгән зат тарафыннан теркәлә. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенда шулай ук хәлиткеч тавыш бирү хокукыннан башка, теләк белдергән бүтән гражданнарга, әгәр җыенда фикер алышына торган мәсьәләләрне хәл итү аларның эшчәнлеге белән бәйле булса, предприятие, учреждение, оешма житәкчеләренә, матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә катнашырга рөхсәт ителә.

3.3. Торак пунктның сайлау хокукына ия яшәүчеләре исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче әлеге муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан теркәлергә һәм җыенында катнашырга мөмкин.

3.4. Язмаларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавын) гражданинның шәхесен раслаучы документ булу раслый ала (Россия Федерациясе гражданы паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт).

3.5. Гражданнар җыены анда сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Кворум булмаганда, гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасы муниципаль берәмлек Башлыгы тарафыннан билгеләнә. Бу очракта гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртәрәк булмаган вакытта үткәрелергә тиеш.

3.6. Гражданнар җыены этаплап уздырылган очракта, аерым этапларында гражданнарның килүе барлык уздырылган этаплар йомгаклары буенча тавышларны санап хокуклы була, ягъни бер җыен буларак санала.

3.7. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яисә яшерен булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турында карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә.

3.8. Яшерен тавыш бирү уздырганда, гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданга тавыш бирү өчен бюллетень бирелә.

3.9. Гражданнар җыенында муниципаль берәмлек Башлыгы яисә теркәлгән гражданнар җыенында катнашучылар саныннан ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.10. Гражданнар җыены секретарь һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзалары саны өч кешедән ким була алмый.

Хисап комиссиясенә рәислек итүче һәм секретарь керә алмый.

Хисап комиссиясе вәкаләтләре:

1) гражданнар җыенына килгән халыкның дөрес теркәлүен, кирәк булган очракта аларнын гражданнар җыены эшендә катнашуга хокукларын тикшерә;

2) гражданнар җыены (йомгаклау) кворумын билгели (гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш);

3) тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;

4) тавышларны саный һәм тавыш бирүгә йомгак ясый (гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш);

5) тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи (гражданнар җыены этаплары йомгаклары буенча);

6) рәислек итүчегә тавыш бирү нәтиҗәләре белән материалларны (беркетмә, җыен этапларында катнашучы гражданнар исемлеге) тапшыра.

3.11. Гражданнар җыенын этаплап үткәрү вакытында муниципаль берәмлек Башлыгы яисә теркәлгән гражданнар җыенында катнашучылар саныннан ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын җыенда катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.12. Җыен этапларында тавыш бирү ачык яисә яшерен булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турында карар гражданнар җыены этабында кабул ителә.

3.13. Гражданнар җыенын этаплап үткәргәндә һәр этапның хисап комиссиясе арасыннан гражданнарның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча хисап комиссиясенең бер әгъзасы сайлана, алар кворумны һәм йомгаклау тавышларын санаганда комиссия составында эшләячәк.

3.14. Гражданнар җыены авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан ачыла. Гражданнар җыенында рәислек итүче гражданнар җыенын үткәрүне оештыра, тәртип саклый, хисап комиссиясе эшен көйли, фикер алышына торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.15. Гражданнар җыенында секретарь тарафыннан беркетмә алып барыла, анда түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданнар җыенын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны.

3.16. Гражданнар җыенын этаплап үткәргәндә, беркетмә һәр этапта алып барыла, соңыннан алар үткәрелгән гражданнар җыены этаплары йомгаклары буенча җыенның бер йомгаклау беркетмәсенә рәсмиләштерелә, шулай ук хисап комиссиясенең беркетмәләре гражданнар җыенының һәр этабында тавышларны санау нәтиҗәләре буенча хисап комиссиясенең бер йомгаклау беркетмәсенә рәсмиләштерелә.

3.17. Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе гражданнар җыены этапларын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, гражданнар җыены этапларында катнашкан

гражданнарның гомуми саны турында, гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирүнең йомгаклау нәтиҗәләре турында белешмәләрне үз эченә ала.

Йомгаклау беркетмәсе җирлек башлыгы кул куя торган гражданнар җыены карарын рәсмиләштерү өчен нигез булып тора, ул махсус мәгълүмати стендларда: Круглое Поле поселогы, Вокзал ур., 7 й.,Локомотив ур., 19 й.; Мәктәп ур., 8 й., мәгълүмат стенды; Вокзал ур., 9А й, мәгълүмат стенды; Төзүчеләр ур., 7 й, мәгълүмат стенды.

һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (http://tukay.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелә.

3.18. Беркетмәгә җыенда рәислек итүче, җыен секретаре тарафыннан кул куела һәм ул муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда катнашучылар исемлеге теркәлә.

3.19. Үткәрелгән гражданнар җыены этапларының нәтиҗәләре буенча хисап комиссиясенең йомгаклау беркетмәсе гражданнар җыены этапларын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, үткәрелгән җыен этапларының саны, гражданнар җыеннарының уздырылган этаплары буенча хисап комиссиясе беркетмәләре саны, җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм аларның эшендә катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны, тавышларның гомуми саны турында белешмәләрне үз эченә ала.

3.20. Йомгаклау беркетмәсенә хисап комиссиясе рәисе һәм хисап комиссиясе әгъзалары тарафыннан кул куела һәм ул муниципаль берәмлек Башлыгына тапшырыла.

## 4. Гражданнар җыены карарлары

4.1. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый акт булып тора, муниципаль берәмлек Башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары җирлек уставы белән билгеләнгән вәкаләтләрне бүлешү нигезендә гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яки үзгәртелергә мөмкин яисә суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар махсус мәгълүмати стендларда: Круглое Поле поселогы, Вокзал ур., 7 й.,Локомотив ур., 19 й.; Мәктәп ур., 8 й., мәгълүмат стенды; Вокзал ур., 9А й, мәгълүмат стенды; Төзүчеләр ур., 7 й, мәгълүмат стенды һәм Тукай муниципаль районынын рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (http://tukay.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш һәм муниципаль хокукый актлар өчен таләпләр нигезендә рәсмиләштерелә.

## Гражданнар җыены карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслауга мохтаҗ түгел.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларның үтәлмәвенә закон нигезендә җаваплылык каралган.